ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләре һәм статусы турында» һәм «Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керүче «Кощаково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләрен һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керүче «Кощаково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләре чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.


**2 статья**

«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләре һәм статусы турында» 2004 елның 15 сентябрендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 8 – 9; 2007, № 12 (II өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (VI өлеш); 2012, № 1; 2014, № 12 (IV өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләре һәм статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләре
**карта схемасы**




Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең чиктәш чикләре тасвирламасы

43-44 - Биектау муниципаль районы
44-45 - Питрәч муниципаль районы
45-41 - Лаеш муниципаль районы
41-40 - Югары Ослан муниципаль районы
40-43 - Зеленодольск муниципаль районы";

Шартлы билгеләр

- Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чиге

41 - тоташу ноктасының тәртип саны

2) 2 нче кушымтада:

а) илле бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«шуннан соң чик 595 м көньяк-көнчыгышка таба Казан шәһәренең әйләнеп үтә торган автомобиль юлына бирелгән полоса буйлап, аннары 105 м көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының төньяк-көнчыгыш ахырына кадәр, аннары 860 м көньяк-көнчыгышка таба Казан шәһәренең әйләнеп үтә торган автомобиль юлына бирелгән полоса буйлап, аннары 1350 м көньяк-көнчыгышка таба, Казан шәһәренең әйләнеп үтә торган автомобиль юлы күчәреннән 55 м көньяк-көнбатышта Киндерка елгасын кисеп үтеп, аннары 1250 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары Казан шәһәренең әйләнеп үтә торган автомобиль юлы кучәреннән 60 м ераклыкта Чабакса авылына керү юлын кисеп үтә, аннары көньяк-көнчыгышка таба 825 м Казан шәһәренең әйләнеп үтә торган автомобиль юлына бирелгән полоса буйлап Казан шәһәре муниципаль берәмлеге, Биектау һәм Питрәч муниципаль районнары чикләре тоташкан җирдә Биектау муниципаль районының Эстачи авылыннан 2,76 км көньяк-көнбатышта урнашкан 44 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

б) илле алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чиге «Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 44 нче тоташу ноктасыннан алып 1,7 км көньякка таба Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 45 м көнчыгышка таба, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап 370 м төньякка таба уза, шуннан соң урман полосасының көньяк чиге буйлап 585 м көньяк-көнчыгышка, сынык сызык ясап, 435 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 105 м «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биектау участок урманчылыгындагы 163 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 315 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 175 м 163 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 320 м көньяк-көнбатышка таба, урман массивын кисеп үтеп, 625 м төньяк-көнбатышка таба, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 310 м көньяк-көнбатышка таба бара, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап 2,07 км көньякка таба, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 550 м төньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, Казан – Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м көньяк-көнчыгышка таба, 100 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м көнчыгышка таба урман полосасының төньяк чиге буйлап, 160 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 300 м «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Столбище участок урманчылыгындагы 99 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап, 5,68 км көньяк-көнчыгышка таба Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап, 80 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең

Столбище участок урманчылыгындагы 103 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 910 м һәм көньяк, көньяк-көнбатыш чикләре буйлап 170 м төньяк-көнбатышка таба, күмәк бакчаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 65 м көньяк-көнбатышка таба, буаның сул ягы буйлап 230 м көньякка таба, 160 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Крутовка елгасы агымы буенча 570 м аска таба аның Нокса елгасына койган урынына кадәр бара, әлеге елга агымы буенча 3,89 км аска таба уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 615 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, яр буе агач-куак полосасын һәм Нокса елгасы ярының текә кишәрлеген кисеп үтеп, кибеп баручы инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча, Питрәч муниципаль районының Көек авылын Казан – Салмачы автомобиль юлы белән тоташтыручы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,92 км өскә таба бара, аннары 260 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 720 м көньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешне һәм чокырларны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 2,66 км көньяк-көнчыгышка таба, 1,9 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 50 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Казан шәһәре муниципаль берәмлеге, Питрәч һәм Лаеш муниципаль районнары чикләре тоташкан җирдә Питрәч муниципаль районының Көек авылыннан 50 м көньякта урнашкан 45 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

в) илле җиденче – алтмыш алтынчы абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга.

**3 статья**

«Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (III өлеш); 2007, № 12 (II өлеш); 2008, № 7 (I өлеш), № 12 (VIII өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2014, № 11 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Питрәч муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында" Татарстан
Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Питрәч муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре

# **карта-схемасы**



Шартлы билгеләр

- муниципаль район чиге
33 - тоташу ноктасының тәртип саны
10 - жирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- жирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның
чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 43(45)-42(44) | - Казан шәһәре муниципаль берәмлеге |
| 42(44)-1(46) | - Биектау муниципаль районы |
| 1(46)-4(48) | - Арча муниципаль районы |
| 4(48)-13(55) | - Теләче муниципаль районы |
| 13(55)-26(56) | - Балык Бистәсе муниципаль районы |
| 26(56)-43(45) | - Лаеш муниципаль районы |

«Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче авыл җирлекләре

| Карта-схемада № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Белкино авыл җирлеге |
| 2 | Богородский авыл җирлеге |
| 3 | Екатериновка авыл җирлеге |
| 4 | Кибәч авыл җирлеге |
| 5 | Кибәк Иле авыл җирлеге |
| 6 | Кавал авыл җирлеге |
| 7 | Күн авыл җирлеге |
| 8 | Кощаково авыл җирлеге |
| 9 | Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге |
| 10 | Колай авыл җирлеге |
| 11 | Ленино-Кокушкино авыл җирлеге |
| 12 | Надеждино авыл җирлеге |
| 13 | Татар Казысы авыл җирлеге |
| 14 | Пановка авыл җирлеге |
| 15 | Питрәч авыл җирлеге |
| 16 | Пимәр авыл җирлеге |
| 17 | Татар Тау Иле авыл җирлеге |
| 18 | Чыты авыл җирлеге |
| 19 | Шәле авыл җирлеге |
| 20 | Шигали авыл җирлеге |
| 21 | Янсуар авыл җирлеге |

»;

2) 2 нче кушымтаның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге Казан шәһәре муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 42 нче (44 нче) тоташу ноктасыннан алып 1,7 км көньякка таба Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 45 м көнчыгышка таба, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап 370 м төньякка таба уза, шуннан соң урман полосасының көньяк чиге буйлап 585 м көньяк-көнчыгышка, сынык сызык ясап, 435 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 105 м «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биектау участок урманчылыгындагы 163 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 315 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 175 м 163 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 320 м көньяк-көнбатышка таба, урман массивын кисеп үтеп, 625 м төньяк-көнбатышка таба, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 310 м көньяк-көнбатышка таба бара, әлеге

автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап 2,07 км көньякка таба, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 550 м төньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, Казан – Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м көньяк-көнчыгышка таба, 100 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м көнчыгышка таба урман полосасының төньяк чиге буйлап, 160 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 300 м «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Столбище участок урманчылыгындагы 99 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап, 5,68 км көньяк-көнчыгышка таба Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап, 80 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Столбище участок урманчылыгындагы 103 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 910 м һәм көньяк, көньяк-көнбатыш чикләре буйлап 170 м төньяк-көнбатышка таба, күмәк бакчаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 65 м көньяк-көнбатышка таба, буаның сул яры буйлап 230 м көньякка таба, 160 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Крутовка елгасы агымы буенча 570 м аска таба аның Нокса елгасына койган урынына кадәр бара, әлеге елга агымы буенча 3,89 км аска таба уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 615 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, яр буе агач-куак полосасын һәм Нокса елгасы ярының текә кишәрлеген кисеп үтеп, кибеп баручы инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча, Питрәч муниципаль районының Көек авылын Казан – Салмачы автомобиль юлы белән тоташтыручы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,92 км өскә таба бара, аннары 260 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 720 м көньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешне һәм чокырларны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 2,66 км көньяк-көнчыгышка таба, 1,9 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 50 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 43 нче (45 нче) тоташу ноктасына кадәр бара.».

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты


Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 13 июль
№ 53-ТРЗ

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләре һәм статусы турында» һәм «Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

# Үзгәрешләрне исәпкә алып, муниципаль берәмлекләр чикләренең карта-схемасы




Шартлы билгеләр

- Питрәч муниципаль районы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чикләре

- муниципаль берәмлекләр чикләре

- А-Б - Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл жирлегенең һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге

- жирлекләрнең административ үзәкләре

- торак пунктлар

- Питрәч муниципаль районының һәм аның составына керүче Кощаково авыл жирлегенең Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелә торган территориясе